РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«20» январь 2023г.

№ 4

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 24 ноябрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нең 2022 елның 19 декабрендәге 382 номерлы хатын карап, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, «2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2022 елның 1 сентябрендәге 934 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача бәясен оештыру һәм аларга түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 елның 3 октябрендәге 1065 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Бшакарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 24 ноябрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына (08.02.2016 № 41, 29.01.2017 № 34, от 20.06.2017 № 328, 29.12.2018 № 879, 16.11.2020 № 498, 31.12.2020 № 620, 15.02.2021 № 55, 19.03.2021 № 124, 29.12.2021 № 325, 10.10.2022 № 197, 13.12.2022 № 266 карарлар редакциясендә) (алга таба текст буенча - 559 номерлы карар) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар тукландыруны оештырырга: 1-4 сыйныфлар өчен 64 сум 19 тиен түләүсез кайнар туклану, 5-11 сыйныфлар өчен һәр уку көненә һәм ата-аналар түләвенә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидиядән торган суммага.

1.2. 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдән укучылар өчен һәр уку көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүне оештырырга. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләве җирле бюджет хисабына түләнергә тиеш. Үз составында 4 һәм аннан да күбрәк бала булган, биләүче гаиләләрдән (тәрбиягә бала алучы һәм опекун гаиләләреннән) укучылар түләүсез кайнар туклану белән тәэмин ителергә тиеш түгел.

1.2.1. 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр ике ата-анасы да үлгән ятим балалар, атасы яки анасы тәрбиясеннән мәхрүм калган ятим балалар өчен һәр уку көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүне оештырырга. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләве җирле бюджет хисабына түләнергә тиеш.

1.2.2. 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр ата-анасының берсе 1 төркем инвалид ике һәм аннан күбрәк балаларны тәрбияләүче гаиләләрдән булган укучылар өчен һәр уку көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүне оештырырга. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләве җирле бюджет хисабына түләнергә тиеш.

1.2.3. 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр ата-ананың берсе бер бала тәрбияләүче 1 төркем инвалид җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдәге укучылар өчен һәр уку көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүне оештырырга. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләве җирле бюджет хисабына түләнергә тиеш.

1.2.4. 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен һәр уку көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүне оештырырга. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләве җирле бюджет хисабына түләнергә тиеш.

1.2.5. 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарнын, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең гаиләләрендәге (гаилә әгъзаларын), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләре гаиләләрендәге (гаилә әгъзаларына) укучыларны, һәр уку көненә һәм ата-ана

түләвенә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидиядән торучы, кайнар туклану белән тәэмин итәргә. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләве җирле бюджет хисабына түләнергә тиеш. Ташлама хәрби комиссариатның мәгариф оешмасында укучының гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе, гражданның махсус хәрби операция чорында хезмәт узуы турында башка дәүләт органнарының раслаучы документлары нигезендә бирелә.

1.3. Өйдә белем алучы 1-4 сыйныф укучыларын җирле бюджеттан көнгә 8,80 сумга азык-төлек җыелмасы (коры аш) белән тәэмин итәргә.

1.4. Озынайтылган көн төркеме укучылары өчен җирле бюджеттан көнгә 8,80 сумга күләмендә бушлай кайнар туклану белән тәэмин итәргә.».

2. Карарның 2.1 пунктында «2022» санын «2023» санына алмаштырырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 9 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин